Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл жирлегенең
Югары Субаш торак пунктында
ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

"28" ноябрь, 2023 ел

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, 23.1 Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Уставы һәм «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар жыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 21.10.2019 № 116 карары, «гражданнар җыенын үткәрү инициативасы турында» 2023 елның 10 ноябрендәге 4 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлегенен Югары Субаш:

1.2024 елда авыл жирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. Югары Субаш авыл жирлегенең 1 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкәннәрдән, эшкә сәләтсез гражданнардан, үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә сәләтсез гражданнардан, армия сафларында срочная хезмәт үтә торган затлардан, ялгыз аналардан, гаиләләрдән, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаган балалары булган затлардан, теркәлгән, әмма яшәү урыны буенча яшәмәгән затлардан тыш. Бөек Ватан сугышы тол хатыннары, мобилизацион гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, алар өчен үзара салым суммасының 90% күләмендә ташлама билгеләнгән: көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар өчен үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Югары Субаш авылында су белән тәэмин итү системасын төзекләндерү.

2. Югары Субаш авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән гражданнар жыены нәтижәләрен игълан итәргә http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында http://baltasi.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен жибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе

А.А.ХӨСНЕТДИНОВ